РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

РАСПОРЯЖЕНИЕ КҮРСӘТМӘ

31.10.2015 Олы Кайбыч ав. № 13

Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының «Коррупциягә юк дибез!» темасына иң яхшы иҗади эшләр район конкурсы үткәрү турында

Коррупциягә каршы җәмәгатьчелек фикере формалаштыру һәм коррупция белән килешмәү, коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыруга җәлеп итү максатларында:

1. Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының «Коррупциягә юк дибез!» темасына иң яхшы иҗади эшләр район конкурсы игълан итәргә.

2. Расларга:

2.1. «Коррупциягә юк дибез!» темасына иң яхшы иҗади эшләр район конкурсы турында нигезләмәне (1нче кушымта).

2.2. Конкурс комиссиясе составын (2 нче кушымта).

2.3. Конкурс уздыру чыгымнары сметасын (3нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе Михайлова Л.Г. га конкурсны уздыру өчен финанслау чыганакларын табарга.

4. Әлеге күрсәтмәне массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.

5. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәш буенча ярдәмчесе Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

А.И. Рәхмәтуллин